Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең
Сабанча торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы

КАРАРЫ

13 декабрь 2020 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 11 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: "Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Сабанча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Сабанча авылы юлларын норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 99 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 53 кеше, бу 53,5% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 53 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сабанча авыл җирлегенең Кәләй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сабанча авыл җирлегенең Кәләй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 1500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: Сабанча авылы юлларын норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Сабанча авылы, Яббарова урамы 1 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Д. Нурзаринов